**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ**
**IV чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**IV созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
20 нче май 2025 ел

**РЕШЕНИЕ**
№45-09

Җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарына тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 4 пункты, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 16 статьясының 4 пункты, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының әйләнә-тирә мохитне саклау буенча вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш, Актанышбаш, Аеш, Аккүз, Әтәс, Югары Яхшый, Кәзкәй, Киров, Күҗәкә, Мәсәде, Яңа Әлем, Пучы, Иске Айман, Иске Байсар, Иске Богады, Иске Сәфәр, Иске Кормаш, Такталачык, Татар Ямалы, Татар  Суыксу, Теләкәй, Түке, Уразай, Усы, Чалманарат, Чуракай авыл җирлекләре башкарма комитетларына тапшырырга.

2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Актаныш муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетлары арасында килешү проектын расларга (1 нче кушымта).

3. Актаныш муниципаль районы башкарма комитетына:

- Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш, Актанышбаш, Аеш, Аккүз, Әтәс, Югары Яхшый, Кәзкәй, Киров, Күҗәкә, Мәсәде, Яңа Әлем, Пучы, Иске Айман, Иске Байсар, Иске Богады, Иске Сәфәр, Иске Кормаш, Такталачык, Татар Ямалы, Татар  Суыксу, Теләкәй, Түке, Уразай, Усы, Чалманарат, Чуракай авыл җирлекләре башкарма комитетлары белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

-әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советының 2025 елга  2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы бюджеты турындагы карарына үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын эшләү һәм бюджет законнары нигезендә карауга тапшырырга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында: http:/aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

Актаныш муниципаль районы
Советы рәисе Л.Р.Зарипов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА ОГРН 1051667000734 ИНН 1604006751